ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.06.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1714**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 августындагы 1652 номерлы карары белән расланган. «Зеленодольск муниципаль районы» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан делегацияләрне, аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә һәм чаралар үткәрүгә чыгымнар турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 4 пунктын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018елның 11 августындагы 1652 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан делегацияләрне, аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә һәм чаралар үткәрүгә чыгымнар турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.4.3 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты катнашында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе катнашында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин